| | |
|---|---|
| **ГЛАВА КАВЗИЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘҮҖИЯК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 10 ноябре №3

Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Петровка авылында 2026 елда үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районының Кәүҗияк авыл җирлеге Уставының 18.1 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар кабул итте:

1. 2025 елның 24 ноябрендә 09.00 сәгатькә түбәндәге адрес буенча Петровка авылында: ТР, Сарман муниципаль районы, Петровка авылы, Пушкин урамы, 10 йорт, 2026 елда Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Петровка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2026 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы? Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Петровка авылы, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, хәрби хезмәт, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт узучы һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүче:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ-82 тракторын тоту: дизель ягулыгы, дизмай, зап часть сатып алу);
2) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау; урамнарны яктырту җайланмаларын урнаштыру (Петровка торак пунктында энергияне саклый торган

лампалар сатып алу һәм урнаштыру, яктырткычларны һәм урамнарны яктырту лампаларын алыштыру).

"ӘЙЕ "            " ЮК?».

3. Әлеге карарны Кәүҗияк авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә.
4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге
Башлыгы                                        Ф.Ә.Хөснетдинов